ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында җәмәгать контролен (алга таба – җәмәгать контроле) оештыруның һәм гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләрен җайга сала.

2. Җәмәгать контролен гамәлгә ашыру "Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында" 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар белән җайга салына.

3. Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

2 статья. **Җәмәгать контролен гамәлгә ашыру рәвешләре һәм тәртибе**

1. Җәмәгать контроле җәмәгать мониторингы, җәмәгать тикшерүе, җәмәгать экспертизасы рәвешләрендә, Федераль законга каршы килми торган башка рәвешләрдә, шулай ук граждан җәмгыяте институтларының дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән җәмәгать фикер алышулары, җәмәгать (гавами) тыңлаулары кебек үзара эшчәнлеге рәвешләрендә һәм үзара эшләүнең башка рәвешләрендә гамәлгә ашырыла.

2. Җәмәгать контроле бер үк вакытта берничә рәвештә үткәрелә ала.

3. Җәмәгать контролен әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән рәвешләрдә гамәлгә ашыру тәртибе Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнә.

3 статья. **Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы**

1. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы "Россия Федерациясе субъектлары иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында" 2016 елның 23 июнендәге 183-ФЗ номерлы Федераль законда, "Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында" 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган тәртиптә җәмәгать контролен гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җәмәгать контроленең башка субъектлары, органнар һәм оешмалар белән үзара эшли.

4 статья. **Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең иҗтимагый советлары**

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең иҗтимагый советлары әлеге советларның эшчәнлеген җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә җәмәгать контролен гамәлгә ашыралар.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең иҗтимагый советлары җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә җәмәгать контроленең башка субъектлары, органнар һәм оешмалар белән үзара эшлиләр.

5 статья. **Җәмәгать инспекцияләре һәм җәмәгать контроле төркемнәре**

1. Җәмәгать инспекцияләре һәм җәмәгать контроле төркемнәре, законнар үтәлешенә ярдәм итү, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, җәмгыять мәнфәгатьләрен исәпкә алу максатларында иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең аерым өлкәләрендә үзләренә карата җәмәгать контроле үткәрелә торган органнарның һәм (яисә) оешмаларның эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) башкару компетенциясе кергән дәүләт хакимияте органнары белән үзара эшчәнлектә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру өчен Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән җәмәгать контроле субъектлары тарафыннан, шул исәптән гражданнар тәкъдимнәре буенча төзелә.

2. Җәмәгать инспекцияләре иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең берничә өлкәсендә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру өчен төзелә. Җәмәгать инспекциясенең санлы составы биш кешедән ким һәм 15 кешедән артык була алмый.

3. Җәмәгать контроле төркемнәре иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең бер өлкәсендә йә җәмәгать контроленең бер мәсьәләсе буенча җәмәгать контролен гамәлгә ашыру өчен төзелә. Җәмәгать контроле төркеменең санлы составы өч кешедән ким һәм тугыз кешедән артык була алмый.

4. Җәмәгать инспекциясе яисә җәмәгать контроле төркеме әгъзасы булып Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче, 18 яшенә җиткән һәм җәмәгать инспекциясе яисә җәмәгать контроле төркеме әгъзасы буларак җәмәгать эше алып барырга үз ихтыяры белән теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы керә ала.

5. Җәмәгать инспекцияләре һәм җәмәгать контроле төркемнәре:

1) тикшереп тору (күзәтчелек итү) чараларын гамәлгә ашыру барышында дәүләт хакимияте органнары тарафыннан үткәрелә торган тикшерү материаллары белән танышалар, моңа дәүләт сере булган белешмәләрне, персональ мәгълүмат турында белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмат һәм файдалана алуы федераль законнар белән чикләнгән мәгълүмат керми;

2) җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча Федераль закон таләпләре нигезендә йомгаклау документы әзерлиләр.

6. Җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда җәмәгать инспекцияләре һәм җәмәгать контроле төркемнәре җәмәгать контроле субъектлары өчен Федераль законда билгеләнгән башка хокуклардан файдаланалар һәм бүтән бурычларны башкаралар.

7. Законнар үтәлешенә ярдәм итү, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, җәмгыять мәнфәгатьләрен исәпкә алу максатларында иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең аерым өлкәләрендә үзләренә карата җәмәгать контроле үткәрелә торган органнарның һәм (яисә) оешмаларның эшчәнлегенә муниципаль контрольне башкару компетенциясе кергән җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлектә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы җәмәгать инспекцияләре һәм җәмәгать контроле төркемнәре вәкаләтләре, аларны оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе Федераль законда, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнә.

**6 статья. Җәмәгать контроле субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт оешмаларына һәм муниципаль оешмаларга керү очраклары һәм тәртибе**

1. Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән җәмәгать контроле субъектлары дәүләт хакимияте органнарына һәм федераль законнар нигезендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларына, башка органнарга һәм оешмаларга (алга таба – дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт оешмалары) түбәндәге очракларда керергә хокуклы:

1) җәмәгать тикшерүен үткәргәндә;

2) дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт оешмалары тарафыннан кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган башка оешмалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен массакүләм бозу турында мәгълүмат алынганда.

2. Җәмәгать контроле субъекты дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт оешмаларына, аларга керү датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча, күрсәтелгән органнарга һәм оешмаларга керү турында язма хәбәрнамә җибәрә.

3. Җәмәгать контроле субъекты хәбәрнамәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) керүнең сәбәбе һәм максаты;

2) керү датасы һәм вакыты, җәмәгать тикшерүен үткәрүнең күз алдында тотылган сроклары;

3) җәмәгать контроле субъекты тарафыннан керү вәкаләте бирелгән затларның персональ составы;

4) өйрәнү өчен планлаштырыла торган документларның якынча исемлеге;

5) тәкъдим ителә торган бару регламенты;

6) элемтәгә керү өчен мәгълүмат.

4. Җәмәгать контроле субъекты хәбәрнамәсе почта аша, факсимиль элемтә ярдәмендә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә электрон почта аша җибәрелергә мөмкин.

5. Дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт оешмалары, җәмәгать контроле субъекты хәбәрнамәсен алганнан соң, хәбәрнамәне алган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, керү датасын һәм вакытын язмача расларга һәм җәмәгать контроле субъектының дәүләт хакимияте органына, дәүләт оешмасына керә алуын тәэмин итәргә йә җәмәгать контроле субъекты белән башка керү датасын һәм вакытын килештерергә, йә, федераль законнарда каралган очракларда, керүне кире кагу турында хәбәр итәргә тиеш.

6. Җәмәгать контроле үткәрелә торган дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт оешмаларына керү бары тик күрсәтелгән органнарның һәм оешмаларның эш сәгатьләрендә генә башкарыла ала һәм аларның эшчәнлегенә комачауларга тиеш түгел.

7. Җәмәгать контроле үткәрелә торган дәүләт хакимияте органнарында һәм дәүләт оешмаларында гражданнар керүнең махсус тәртибе булса, күрсәтелгән органнарга һәм оешмаларга керү билгеләнгән тәртип нигезендә башкарыла.

8. Җәмәгать контроле субъектларының җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль оешмаларга, федераль законнар нигезендә аерым муниципаль вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка органнарга һәм оешмаларга керү очраклары һәм тәртибе муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнә.

7 статья. **Җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документларын дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар тарафыннан карау**

1. Җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документларын дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт оешмалары һичшиксез карарга тиеш.

2. Дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт оешмалары аларга җибәрелгән җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документларын карыйлар һәм федераль законнарда билгеләнгән срокта җәмәгать контроленең тиешле субъектларына нигезләнгән җаваплар җибәрәләр.

3. Җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документларындагы тәкъдимнәр, рекомендацияләр һәм нәтиҗәләр тиешле дәүләт

хакимияте органнары һәм дәүләт оешмалары компетенциясенә кергән, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән һәм аларда дәүләт хакимияте органнары яисә дәүләт оешмалары тарафыннан кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган башка оешмалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу күрсәтелгән очракта, әлеге тәкъдимнәр, рекомендацияләр һәм нәтиҗәләр дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт оешмалары үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда алар тарафыннан һичшиксез исәпкә алынырга тиеш.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган очракта дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт оешмалары кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган башка оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау чараларын күрергә тиеш.

5. Әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән очракта җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документларындагы тәкъдимнәр, рекомендацияләр һәм нәтиҗәләр федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларының, башка органнар һәм оешмаларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

6. Җирле үзидарә органнарының, муниципаль оешмаларның, федераль законнар нигезендә аерым муниципаль вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка органнарның һәм оешмаларның эшчәнлегенә җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документларындагы тәкъдимнәрне, рекомендацияләрне һәм нәтиҗәләрне исәпкә алу, шул исәптән муниципаль оешмаларның, федераль законнар нигезендә аерым муниципаль вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка органнарның һәм оешмаларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алу очраклары муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнә.

8 статья. **Җәмәгать контроле нәтиҗәләрен халыкка игълан итү**

1. Җәмәгать контроле субъектлары үз эшчәнлекләре турындагы, үткәрелә торган җәмәгать контроле чаралары хакындагы һәм аларның нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Федераль законда билгеләнгән тәртиптә халыкка игълан итәләр.

2. Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар үзләре башкара торган эшчәнлеккә җәмәгать контроле мәсьәләләре буенча мәгълүматны үзләренең "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштыралар.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 20 июль
№ 62-ТРЗ